РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

14 ноябрь 2019 ел № 252

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2017 елның 13 декабрендәге 130 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген раслау турында» карарына өстәмәләр кертү хакында

Чирмешән муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында, «Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясына нигезләнеп Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2017 елның 13 декабрендәге 130 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендә булган, өченче затларның (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукларыннан азат булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән

муниципаль мөлкәт исемлеген раслау турында»гы карары (район Советының 2018 елның 13 декабрендәге 199 номерлы карары белән кабул ителгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендәге муниципаль милекнең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ия булу (владение) һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән исемлеген киләсе эчтәлектә тулыландырырга:

| № п/п | Мөлкәт атамасы | Милекнең урнашу урыны | Мәйданы (кв. м.) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2нче номерлы бинаның өлеше | Татарстан Республикасы, Чирмешән районы, Чирмешән авылы, Титов урамы, 22нче йорт | 58,2 |
| 2 | 3нче номерлы бинаның өлеше | Татарстан Республикасы, Чирмешән районы, Чирмешән авылы, Титов урамы, 22нче йорт | 59,0 |
| 3 | 4нче номерлы бинаның өлеше | Татарстан Республикасы, Чирмешән районы, Чирмешән авылы, Титов урамы, 22нче йорт | 50,0 |
| 4 | Сәүдә объектларын урнаштыру өчен җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Чирмешән авыл җирлеге, Чирмешән авылы, Гагарин ур. Кадастр номеры: 16: 41:080124:33 | 5390 |
| 5 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Чирмешән авыл җирлеге Кадастр номеры: 16: 41:080402:517 | 52376 |
| 6 | Иҗтимагый-эшлекле әһәмияттәге объектлар өчен җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Чирмешән авыл җирлеге, Чирмешән авылы Кадастр номеры: 16: 41:080402:658 | 103849 |
| 7 | Эшмәкәрлек җир кишәрлеге (агросәнәгать паркы) | Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Лашман авылы, Химиклар ур., 39А Кадастр номеры: 16:41:040103:395 | 59305 |

2. Әлеге карарны «Безнең Чирмешән» («Наш Черемшан») район газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты Җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасарына һәм район Советының икътисади сәясәт һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Советы рәисе Ф.М. Дәүләтшин